КАРАР

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлегенең Олы Бортас авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2024 елның 15 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча 2024 елның 15 ноябрендә узган халык җыены беркетмәсе төзелде. «2025 елда гражданнарның үзара салымын Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлегенең Олы Бортас торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизация буенча мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

- Торак пункт территориясен төзекләндерү;
- Традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар кору, төзекләндерү.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 26 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында 16 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда 16 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы составына керүче Олы Бортас авыл җирлегенең Олы Бортас авылында халык җыенын узган дип танырга, Халык җыенының нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлегенең Олы Бортас торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизация буенча мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- Торак пункт территориясен төзекләндерү;
- Традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар кору, төзекләндерү.

3. 2025 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган

һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизация буенча мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә үзсалым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Торак пункт территориясен төзекләндерү;
- Традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар кору, төзекләндерү.

4. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

-ТР, Кама Тамагы районы, Олы Бортас авылы, Ленинград ур., 27,
-ТР, Кама Тамагы районы, Балчыклы авылы, Ленин ур., 70,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Бортас авыл җирлеге башлыгы Р. С. Сәгдиев